**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

«02» март 2026 ел № 444-р

**2026 елга гражданнарның керемнәре һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясе чикләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасына нигезләнеп, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәп нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында» 2021 елның 23 апрелендәге 395 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты боерык бирә:

1. 2026 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 820 998 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 641 996 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 2 462 994 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 283 992 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 4 104 990 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 4 925 988 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 5 746 986 сум;

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь күрсәткечләре:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 31 982,11 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 31 982,11 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешеле гаилә өчен – 31 982,11 сум.

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Иҗтимагый торак комиссиясенә 1.1 һәм 1.2. пунктчаларында күрсәтелгән керемнең максималь

күләмнәрен торак урыннарга мохтаҗ гражданнар буларак исәпкә куйганда әлеге боерыкны файдаланырга.

3. Әлеге күрсәтмә үз көченә кергән мизгелдән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында» 2025 елның 17 мартындагы 303- р номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин